Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Светлоозерского
сельского поселения Заинского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлегенең
башкарма комитеты

ул. Фардеева, д.15, с. Светлое Озеро,
Заинский район, 423538

Фардеев урамы, 15нче йорт, Якты
Күл авылы, Зәй районы, 423538

Телефон, факс 68-2-88. Электронный адрес: Svoz.Zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/svetloozerskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 31.01.2020 ел.** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Җирләү һәм җирләү эше турында " 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2020 елның 01 февраленнән, 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә, 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **З. З. Мөхтәров**

Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2020 ел №2
карарына 1нче кушымта

Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(2020 елның 01 февраленнән)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 2 343,73 |
| 3. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 944,51 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 836,62 |
| Барлыгы | 6 124,86 |

Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2020 ел №2
карарына 2нче кушымта

**Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә бәяләр (2020 елның 01 февраленнән)**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)* |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү (облачение тела) | 628,31 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1 715,42 |
| 4. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 944,51 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 836,62 |
| Барлыгы | 6 124,86 |